ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 декабрь, 2025 ел № 3/10

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре составын раслау турында

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау Комиссиясе составын 1 нче кушымта нигезендә;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Автозавод районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау Комиссиясе составын 2 нче кушымта нигезендә;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Комсомол районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау Комиссиясе составын 3 нче кушымта нигезендә;

4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Үзәк районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау Комиссиясе составын 4 нче кушымта нигезендә.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау Комиссиясенә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Автозавод, Комсомол, Үзәк районнарының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау Комиссияләренә вәкаләтләрне 5 нче кушымта нигезендә бирергә.

3. Шәһәр Советы Карарларын көчен югалткан дип таныргa:

1) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре составын раслау турында» 2022 елның 23 июнендәге 15/15 номерлы Карарын;

2) «Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре составын раслау турында» 2022 елның 23 июнендәге 15/15 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 29 мартындагы 22/12 номерлы Карарын;

3) «Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре составын раслау турында» 2022 елның 23 июнендәге 15/15 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 29 июнендәге 25/12 номерлы Карарын;

4) «Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре составын раслау турында» 2022 елның 23 июнендәге 15/15 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 6 декабрендәге 28/12 номерлы Карарын;

5) «Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре составын раслау турында» 2022 елның 23 июнендәге 15/15 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 1 июлендәге 34/12 номерлы Карарын;

6) «Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре составын раслау турында» 2022 елның 23 июнендәге 15/15 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 6 декабрендәге 39/11 номерлы Карарын;

7) «Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре составын раслау турында» 2022 елның 23 июнендәге 15/15 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 июнендәге 44/11 номерлы Карарын.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
3/10 Карарына
1 нче кушымта
3 декабрь, 2025 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау Комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Мәһдиев<br>Наил Гамбәр улы | - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (алга таба - Комиссия) рәисе, шәһәр Хакиме; |
| 2. | Харисов<br>Винер Хәмит улы | - Комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары; |
| 3. | Кашапов<br>Нәркиз Венер улы | - Комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы; |
| 4. | Лягуцкая<br>Светлана Рафаиловна | - Комиссиянең җаваплы секретаре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе баш белгече; |
| 5. | Әхмәтҗанов<br>Ленар Илдар улы | - Башкарма комитетның Комсомол район хакимияте башлыгы; |
| 6. | Әхмәтшин<br>Ренат Рөстәм улы | - Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе башлыгы; |
| 7. | Борһанова<br>Айгөл Әбүзәр кызы | - Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча); |
| 8. | Видинеева<br>Ләйсән Әлфит кызы | - Башкарма комитетның яшьләр эшләре буенча идарәсе башлыгы; |
| 9. | Газизова<br>Лилия Габбас кызы | - «Россия балалар - яшүсмерләр үзәге» Федераль дәүләт бюджет учреждениесенен гражданнарны патриотик тәрбияләү өлкәсендәге проектларны һәм |

| | | |
|---|---|---|
| | | программаларны гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәүче эксперты (килешү буенча); |
| 10. | Гыйззәтуллина Альбина Хәлил кызы | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе участок полиция уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар белән эшләү бүлекчәсе (балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәсе) башлыгы - бүлек башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| 11. | Золотарева Лидия Владимировна | - Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары; |
| 12. | Калинин Иван Михайлович | - Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы; |
| 13. | Калинина Ольга Александровна | - «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе департаментының Яр Чаллы шәһәре һәм Тукай районы буенча халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү үзәге идарәсе башлыгы (килешү буенча): |
| 14. | Кәрәмиев Румил Рәүф улы | - Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы; |
| 15. | Курганаева Ася Исааковна | - Шәһәр Советы депутаты, «Чудо-дети» дәвалау педагогикасы үзәге» автономияле коммерциягә карамаган оешманың башкарма директоры (килешү буенча) |
| 16. | Лундовских Ирина Васильевна | - «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры; |
| 17. | Нурмөхәммәтов Илдар Илгиз улы | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округындагы «Ышаныч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры урынбасары (килешү буенча); |

| | | |
|---|---|---|
| 18. | Одинцова<br>Елена Дмитриевна | - Башкарма комитетның мәгариф идарәсе мәктәпкәчә белем бирү бүлеге башлыгы; |
| 19. | Сыйтдикова Эльвира<br>Тәлгать кызы | - Татарстан Республикасы «Беренчеләр хәрәкәте» Гомумроссия иҗтимагый — дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәте җирле бүлекчәсенең өлкән белгече (килешү буенча); |
| 20. | Хәбибуллин<br>Фидәрис Фәндәвис улы | - Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте башлыгы; |
| 21. | Хәмитова<br>Лилия Илсур кызы | - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең әйдәүче белгече; |
| 22. | Ханбиков<br>Айрат Равил улы | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| 23. | Хөснуллин<br>Айрат Шәүкәт улы | - Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте башлыгы; |
| 24. | Шакиров<br>Ленар Мөзәят улы | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль яклау идарәсе башлыгы (килешү буенча); |

Шәһәр Советының
3/10 Карарына
2 нче кушымта
3 декабрь, 2025 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Автозавод районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау Комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Хөснуллин Айрат Шәүкәт улы | - Автозавод районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (алга таба - Комиссия) рәисе, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте башлыгы; |
| 2. | Әлмөхәммәтова Елена Юрьевна | - Комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте башлыгы урынбасары; |
| 3. | Побиванец Виолетта Николаевна | - Комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округындагы «Ышаныч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекчәсе мөдире (килешү буенча); |
| 4. | Сабирова Эльвира Әнвәр кызы | - Комиссиянең җаваплы секретаре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе баш белгече; |
| 5. | Әхмәтшин Руслан Рәфгат улы | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе 3 нче «Үзәк» полиция бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| 6. | Жандарова Халидә Мәхмүт кызы | - Башкарма комитетның Автозавод районы хакимиятенең мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге башлыгы; |
| 7. | Зәйнуллина Филиза Равил кызы | - Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлеге баш белгече; |
| 8. | Капачинская Оксана Леонидовна | - «Яшүсмер» яшүсмерләр-яшьләр клублары үзәге» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном учреждениесенең структур бүлекчәсе мөдире; |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Ладкина Олеся Александровна | - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең әйдәүче белгече; |
| 10. | Маликова Ольга Михайловна | - Татарстан Республикасы «Беренчеләр хәрәкәте» Гомумроссия иҗтимагый — дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең Яр Чаллы муниципаль берәмлегендә эшен оештыру буенча өлкән белгече (килешү буенча); |
| 11. | Мортазина Гүзәл Азат кызы | - Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Республика клиник наркология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы «Яр Чаллы наркология диспансеры» диспансер бүлегенең медицина психологы (килешү буенча); |
| 12. | Муразуллин Гадел Айрат улы | - «Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җинаять – башкарма инспекциясе» федераль казна учреждениесенең Яр Чаллы шәһәре Автозавод районы буенча филиалы башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| 13. | Фәрхетдинова Лүзә Нәзәх кызы | - «Яшьләр ышаныч телефоны» ашыгыч психологик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры; |
| 14. | Хәмзина Айзилә Илгиз кызы | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе «Автозавод» 1 нче полиция бүлегенең участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлегенең (балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәсе) өлкән инспекторы (килешү буенча); |
| 15. | Әмирбәков Раидин Мәүлүтдин улы | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе «Автозавод» 1 нче полиция бүлеге башлыгы (килешү буенча). |

Шәһәр Советының
3/10 Карарына
3 нче кушымта
3 декабрь, 2025 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Комсомол районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау Комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Комсомол районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (алга таба - Комиссия) рәисе, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте башлыгы; |
| 2. | Вәлиева Эльвира Гафур кызы | - Комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте башлыгы урынбасары, халыкны социаль яклау бүлеге башлыгы; |
| 3. | Хамматова Алсу Ринат кызы | - Комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимиятенең мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге башлыгы; |
| 4. | Шәймарданова Светлана Генадьевна | - Комиссиянең җаваплы секретаре, Комсомол районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең баш белгече; |
| 5. | Баязитова Резеда Флюр кызы | - Башкарма комитет каршындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсенең Комсомол районында җәмәгать тәртибен саклау бүлегенең әйдәүче белгече; |
| 6. | Грачева Наталья Александровна | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округындагы «Ышаныч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекчәсенең социаль эш белгече (килешү буенча); |

| | | |
|---|---|---|
| 7. | Давтян<br>Артур Геимович | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсенең «Комсомол» полиция бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| 8. | Зәкиева<br>Ләйсән Равис кызы | - Башкарма комитетының Комсомол районы хакимиятенең халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлеге баш белгече; |
| 9. | Кадыров<br>Илнар Якуб улы | - «Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җинаять – башкарма инспекциясе» федераль казна учреждениесенең Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы буенча филиалы башлыгы (килешү буенча); |
| 10. | Кочергина<br>Алсу Рифгат кызы | - Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлеге баш белгече; |
| 11. | Макарова<br>Людмила Николаевна | - Татарстан Республикасы «Беренчеләр хәрәкәте» Гомумроссия иҗтимагый — дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәте җирле бүлекчәсенең өлкән белгече (килешү буенча); |
| 12. | Мөбарәкова<br>Светлана<br>Александровна | - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Комсомол районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең әйдәүче белгече; |
| 13. | Рогожников<br>Сергей Валентинович | - Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Республика клиник наркология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы «Яр Чаллы наркология диспансеры» диспансер бүлегенең яшүсмерләр кабинеты фельдшеры (килешү буенча); |
| 14. | Шатунов<br>Игорь Юрьевич | -Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе идарәсенең 2 нче «Комсомол» полиция бүлеге участок полиция уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар белән эшләү бүлекчәсе(балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәсе) башлыгы - бүлек башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| 15. | Шиһабетдинова<br>Резеда Фәрит кызы | - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Комсомол районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең әйдәүче белгече. |

Шәһәр Советының
3/10 Карарына
4 нче кушымта
3 декабрь, 2025 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Үзәк районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау Комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Хәбибуллин Фидәрис Фәндәвис улы | - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Үзәк районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (алга таба - Комиссия) рәисе, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте башлыгы; |
| 2. | Гыйлметдинова Эльмира Илгизәр кызы | - Комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте башлыгы урынбасары, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге башлыгы; |
| 3. | Ермолаева Эльвира Маснавиевна | - Комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте халыкны социаль яклау бүлеге башлыгы; |
| 4. | Ибраева Елена Николаевна | - Комиссиянең җаваплы секретаре, Үзәк районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең баш белгече; |
| 5. | Баринова Елена Сергеевна | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе идарәсенең 3 нче «Үзәк» полиция бүлеге участок полиция уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар белән эшләү бүлекчәсе (балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәсе) башлыгы - бүлек башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| 6. | Галимуллина Рузия Ринат кызы | - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең әйдәүче белгече; |
| 7. | Гатауллина Юлия Владимировна | - Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлеге баш белгече; |

| | | |
|---|---|---|
| 8. | Гаянова Лилия Зиннур кызы | - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең әйдәүче белгече; |
| 9. | Кладиенко Ирина Викторовна | - «Яшүсмер» яшүсмерләр-яшьләр клублары үзәге» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном учреждениесенең яшьләр белән эшләү буенча белгече; |
| 10 | Краснова Яна Евгеньевна | - «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Яр Чаллы шәһәре һәм Тукай районы буенча департаментында эш эзләү максатларында һәм эшсезләр сыйфатында теркәлгән гражданнар белән эшләү (икенчел кабул итү) бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| 11 | Орехова Елена Викторовна | - «5 нче балалар шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең медицина психологы (килешү буенча); |
| 12 | Сафиуллина Гүзәлия Җәмил кызы | - «2 нче балалар шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең медицина психологы (килешү буенча); |
| 13 | Сироткин Евгений Александрович | - «Нур» яшьләр үзәге» МАУ директоры (килешү буенча); |
| 14 | Сыйтдикова Эльвира Тәлгать кызы | - Татарстан Республикасы «Беренчеләр хәрәкәте» Гомумроссия иҗтимагый — дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәте җирле бүлекчәсенең өлкән белгече (килешү буенча); |
| 15 | Шәрифуллин Марат Мәүләмҗан улы | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе идарәсенең 4 нче «Электротехник»»» полиция бүлеге участок полиция уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар белән эшләү бүлекчәсе (балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәсе) башлыгы - бүлек башлыгы урынбасары (килешү буенча); |

Шәһәр Советының
3/10 Карарына
5 нче кушымта
3 декабрь, 2025 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре вакәләтләре

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә түбәндәге вакәләтләрне бирергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге дәрәҗәсендә Автозавод, Комсомол, Үзәк районнарның балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре (алга таба – район комиссияләре), балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре эшчәнлеген координацияләү;

2) методик ярдәм күрсәтү, район комиссияләре эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашыру;

3) район комиссияләре эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

4) балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар һәм программалар эшләүдә катнашу;

5) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләрендә балигъ булмаганнар белән эшләү, укыту, карап тоту шартларын үтәүне контрольдә тотуны оештыру;

6) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, караучысызлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау эшенең торышы турында Шәһәр Советына даими мәгълүмат бирү;

7) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә караучысызлык, сукбайлык, наркомания, токсикомания, алкоголизм, хокук бозулар, суицидаль гамәлләр, үлем һәм имгәнүләр, балигъ булмаганнарның торак һәм башка хокукларын бозу турында мәгълүмат, аналитик һәм статистик материаллар җыю, өйрәнү һәм гомумиләштерү, әлеге күренешләрне кисәтү буенча чаралар эшләү һәм оештыру;

8) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау эше турындагы хисапларны, шулай ук сукбайлыкны, күзәтүчесезлекне, наркоманияне, токсикоманияне, алкоголизмны, хокук бозуларны, һәлак булу һәм имгәнүләрне, балигъ булмаганнарның торак һәм башка хокукларын бозуны кисәтү чаралары турында башка мәгълүматны әзерләү һәм җибәрү, әлеге өлкәдә вәзгыятьне яхшырту буенча тәкъдимнәр кертү;

9) муниципаль социаль-тернәкләндерү консилиумнары, эш төркемнәре, эксперт советлары булдыру, социаль-куркыныч хәлдәге гаиләләрне профилактикалау буенча профилактика субъектлары эшен оештыру;

10) дәүләт ярдәменә мохтаҗ балигъ булмаганнар даими яки вакытлыча яши торган дәүләт учреждениеләре (балалар йортлары, приютлар, медицина үзәкләре, тернәкләндерү үзәкләре һәм башка учреждениеләр)белән үзара хезмәттәшлек итү;

11) Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәге, «Н.Ә. Галләмов исемендәге РИШВИ» ДБУ, ябык типтагы Раифа махсус укыту-тәрбия учреждениесе, балигъ булмаганнар өчен тәрбия колонияләре белән үзара хезмәттәшлек итү;

12) җәмәгать берләшмәләре, массакүләм мәгълүмат чаралары, профсоюз, дини һәм башка оешмалар белән балигъ булмаганнарның хокук бозуларын, караучысызлыкны, сукбайлыкны, суицидаль гамәлләрне, наркоманияне, токсикоманияне, алкоголизмны профилактикалау, аларның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек итү;

13) балигъ булмаганнарның, аларның ата-аналарының һәм башка законлы вәкилләренең хокуклары һәм бурычлары өлкәсендә хокукый агарту эше;

14) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясында билгеләнгән һәм әлеге кушымтаның 1 пунктында санап үтелмәгән башка вәкаләтләр район комиссияләре вәкаләтләре булып тора.